ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01 декабрь 2022 ел № 6757

2023-2024 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү куркынычларын профилактикалау программасын раслау турында

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 44, 45 статьялары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Контроль һәм күзәтчелек органнары тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян китерү куркынычларын профилактикалау программасын эшләү һәм раслау кагыйдәләрен раслау турында» 2021 елның 25 июнендәге 990 номерлы карары, Шәһәр Советының «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында нигезләмәне раслау хакында» 2021 енының 3 ноябрендәге 9/14 номерлы карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. 2023-2024 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү куркынычларын профилактикалау программасын (алга таба – профилактикалау программасы) расларга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның административ-техник инспекция идарәсе башлыгы А.З. Хамматовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2022 елның 1 декабрендәге
6757 номерлы карарына
кушымта

2023-2024 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү куркынычларын профилактикалау
программасы

1 бүлек. Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыруның агымдагы торышына анализ, профилактика эшчәнлеге үсешенең агымдагы дәрәҗәсен тасвирлау, профилактика программасы хәл итәргә юнәлдерелгән проблеманың характеристикасы

1. Башкарма комитетның административ-техник инспекция идарәсе (алга таба – Башкарма комитетның АТИ идарәсе) Шәһәр Советының 2021 енһң 3 ноябрендәге 9/14 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында нигезләмә нигезендә төзекләндерү өлкәсендә юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр һәм гражданнар тарафыннан Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренең (алга таба – Төзекләндерү кагыйдәләре), шул исәптән социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектларының һәм күрсәтелә торган хезмәтләрнең инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә карата таләпләрнең үтәлүенә муниципаль контрольне гамәлгә ашыра.

2. Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль объектлары булып тора:

1) биналар, корылмалар, җир участоклары, линия объектлары, алар янындагы территорияләр, контрольдә тотыла торган затлар ия һәм (яки) файдалана торган төзекләндерү элементлары (алга таба-производство объектлары), гомуми файдаланудагы территорияләр;

2) контрольдә тотыла торган затларның производство объектларын, гомуми файдаланудагы территорияләрне карап тоту һәм төзекләндерү тәртибен үтәү буенча эшчәнлеге, гамәлләре (гамәл кылмаулары), шулай ук мондый эшчәнлекнең нәтиҗәләре.

Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә җитештерү һәм башка эшчәнлек башкаручы юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр һәм физик затлар контрольгә алына торган затлар булып торалар.

3. Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль түбәндәгеләр аша гамәлгә ашырыла:

1) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү кагыйдәләрендә каралган мәҗбүри таләпләрнең юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр һәм гражданнар тарафыннан үтәлешенә документлар буенча һәм күчмә тикшерүләр оештыру һәм үткәрү;

2) ачыкланган кимчелекләрне туктату һәм (яки) бетерү буенча Россия Федерациясе законнарында каралган чараларны кабул итү, шулай ук мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен системалы күзәтү;

3) закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян китерү куркынычларын профилактикалау буенча чаралар оештыру һәм үткәрү;

4) юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр һәм физик затлар белән үзара бәйләнешкә кермичә гамәлгә ашырыла торган контроль чараларын оештыру һәм үткәрү.

4. Закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян китерү куркынычларын анализлау һәм бәяләү.

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда мәҗбүри таләпләрне бозуны профилактикалау программасын гамәлгә ашыруда төп һәм аеруча әһәмиятле куркынычлар булып контроль астына алынган субъектлар тарафыннан Россия Федерациясе законнарының, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең төзекләндерү өлкәсендәге норматив хокукый актларының мәҗбүри таләпләрен (алга таба – төзекләндерү өлкәсендәге закон таләпләре) бозу, шул исәптән мәҗбүри таләпләрне бозуга китерергә мөмкин сәбәпләрне, факторларны һәм шартларны юкка чыгару тора.

Контроль астына алынган субъектлар тарафыннан төзекләндерү өлкәсендә мәҗбүри таләпләрне үтәүгә юнәлдерелгән профилактик чаралар үткәрү контроль астына алынган субъектларны намуслылыкка өндәүгә, контроль астына алынган субъектларның җаваплылыгын арттыруга, мәҗбүри таләпләрне бозу очракларын киметүгә юнәлдерелгән.

## 2 бүлек. Профилактика программасын тормышка ашыру максатлары һәм бурычлары

5. Профилактика программасының максатлары:

1) контроль астына алынган субъектларның төзекләндерү өлкәсендә мәҗбүри таләпләрне намус белән үтәвен стимуллаштыру;

2) контроль астына алынган субъектлар тарафыннан төзекләндерү өлкәсендә мәҗбүри таләпләрне бозуга китерергә мөмкин шартларны, сәбәпләрне, факторларны һәм (яки) закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян китерүне бетерү;

3) төзекләндерү өлкәсендәге законнарның мәҗбүри таләпләрен контроль астына алынган субъектларга җиткерү өчен шартлар тудыру, аларны үтәү ысуллары турында хәбәрдарлыкны арттыру.

6. Профилактика программасының бурычлары:

1) контроль астына алынган субъектлар тарафыннан төзекләндерү өлкәсендәге законнарның мәҗбүри таләпләрен бозуга булышучы сәбәпләрне, факторларны һәм шартларны ачыклау, аларны бетерү яки барлыкка килү куркынычын киметү ысулларын билгеләү;

2) профилактик чараларның төрләренең, формаларының һәм интенсивлыгының контроль астына алынган конкрет субъектларның үзенчәлекләренә бәйле булуны билгеләү һәм әлеге факторларны исәпкә алып профилактик чаралар үткәрү;

3) контроль эшчәнлектә катнашучыларның барысында да төзекләндерү өлкәсендәге законнарның мәҗбүри таләпләрен бердәм аңлауны формалаштыру;

4) гамәлгә ашырыла торган контроль эшчәнлекнең ачыклыгын арттыру;

5) контроль астына алынган субъектларның хокукый грамоталылыгы дәрәҗәсен күтәрү, шул исәптән төзекләндерү өлкәсендәге законнарның мәҗбүри таләпләре һәм аларны үтәү буенча кирәкле чаралар турында мәгълүматның һәркем өчен ачык булуын тәэмин итү юлы белән.

7. Профилактика программасы мәҗбүри таләпләрне бозуларны кисәтүнең нәтиҗәлелеген арттыруга һәм контрольдә тотыла торган затларның хокукый грамоталылыгын арттыруга юнәлдерелгән.

## 3 бүлек. Профилактик чаралар исемлеге, аларны үткәрү сроклары (вакыты)

8. Профилактика программасы чаралары әлеге профилактика программасының максатларына ирешү һәм төп бурычларын хәл итүгә юнәлдерелгән чаралар комплексыннан тора.

9. 2023-2024 елларга профилактика програмасының төп профилактик чаралары исемлеге 1 нче таблицада бирелгән.

1 нче таблица

| № т/б | Профилактика чараларының төре | Чараның исеме | Тормышка ашыру срогы | Җаваплы башкаручы |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Мәгълүмат бирү | Профилактика програмасын «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыру, төзекләндерү өлкәсендәге законнарның мәҗбүри таләпләрен үтәү мәсьәләләре буенча мәгълүмат бирү, мәҗбүри таләпләр үзгәргән очракта – яңа таләпләр билгеле торган яңа норматив хокукый актларның эчтәлеге гамәлдәге актларга кертелгән үзгәрешләр, аларның сроклары һәм гамәлгә кертү тәртибе турында аңлатмалар әзерләү һәм тарату | Актуаль хәлдә тоту | Башкарма комитет АТИ идарәсенең баш белгече |
| 2 | Консультацияләр бирү | Юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә һәм физик затларга телефон аша, язма рәвештә, шәхси кабул итүдә яки профилактик чара, контроль чара үткәрү барышында, төзекләндерү өлкәсендәге законнарның мәҗбүри таләпләрен үтәү мәсьәләләре буенча консультация бирү. Шәхсән мөрәҗәгать иткәндә консультация вакыты ун минут тәшкил итә. Календарь ел дәвамында контрольдә тотылучы затлардан һәм аларның вәкилләреннән биш һәм аннан да күбрәк бер типтагы (бер үк сораулар буенча) мөрәҗәгать килгән очракта, консультацияләр Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында (http:nabchelny.ru/) урнаштыру юлы белән гамәлгә ашырыла. | Ел дәвамында | Башкарма комитет АТИ идарәсенең баш белгече |

4 бүлек. Профилактика программасының нәтиҗәлелек күрсәткечләре

10. Профилактика программасын тормышка ашыруның барышын Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының административ-техник инспекция идарәсе контрольдә тота.

11. Профилактика программасын тормышка ашыру мониторингы даими рәвештә башкарыла.

12. Профилактик эш нәтиҗәләре төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турында еллык докладларга кертелә һәм аерым мәгълүмати хәбәр рәвешендә Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштырыла.

13. 2023-2024 елларга профилактика програмасының профилактик чараларын оештыру һәм үткәрү өчен җаваплы вәкаләтле затларның исемлеге 2 нче таблицада бирелгән.

2 нче таблица

| № т/б | Вазыйфа | Функцияләр | Элемтәләр |
|---|---|---|---|
| 1. | Башкарма комитетның АТИ идарәсе башлыгы | Профилактика программасын тормышка ашыру буенча эшчәнлекне оештыру һәм координацияләү | 8(8552)305838<br>Электрон почта<br>mky_ati@mail.ru,<br>Почта адресы:<br>423805, Яр Чаллы шәһәре, Хәсән Туфан проспекты, 23 йорт<br>Гражданнарны кабул итү:<br>сишәмбе 14-00 - 17-00 |
| 2. | Башкарма комитет АТИ идарәсенең җирдән файдалануны һәм яшел утыртмаларның сакланышын контрольдә тоту бүлеге башлыгы | Профилактика програмасы чараларын оештыру һәм үткәрү | 8(8552)305711 |
| 3. | Башкарма комитет АТИ идарәсе җирдән файдалануны һәм яшел утыртмаларның сакланышын контрольдә тоту бүлегенең баш белгече | Профилактика програмасы чараларын оештыру һәм үткәрү | 8(8552)305963 |

14. Профилактика программасының көтелгән нәтиҗәсе – үткәрелә торган профилактика чараларының саны һәм сыйфаты артканда төзекләндерү өлкәсендә законнарның мәҗбүри таләпләрен бозу очракларының кимүе.

15. Профилактик чараларның нәтиҗәлелеген бәяләү методикасы профилактик чаралар үткәргәндә закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә контроль субъектлары тарафыннан китерелгән зыянны (зарарны) киметүнең иҗтимагый әһәмиятле нәтиҗәләренә максималь рәвештә ирешергә ярдәм итү өчен билгеләнгән.

16. Профилактика программасы чараларының максатчан күрсәткечләре:

1) төзекләндерү өлкәсендә ачыкланган закон таләпләрен бозу очраклары саны;

2) үткәрелгән профилактик чаралар саны: массакүләм мәгълүмат чараларында һәм рәсми сайтта бастырып чыгару юлы белән төзекләндерү өлкәсендәге законнарның мәҗбүри таләпләрен үтәү мәсьәләләре буенча контрольдә тотыла торган затларга мәгълүмат бирү; консультация бирү.

17. Нәтиҗәлелек күрсәткечләре:

1) узган хисап чорындагы аналогик күрсәткечләр белән чагыштырганда контроль чаралар үткәргәндә төзекләндерү өлкәсендәге законнар таләпләрен бозуларның ачыкланган санын киметү, берәмлек;

2) узган хисап чорындагы аналогик күрсәткечләр белән чагыштырганда контроль орган тарафыннан үткәрелгән профилактик чаралар саны, берәмлек.

18. Күрсәткеч үткәрелгән профилактик чаралар санының үткәрелгән контроль-күзәтчелек чаралары санына нисбәтеннән исәпләнә.

19. Күрсәткечләрнең кыйммәтләрен билгеләү өчен хисап чоры булып календарь ел тора.

20. Күрсәткечләрнең факттагы (ирешелгән) күрсәткечләрен бәяләү нәтиҗәләре төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне тормышка ашыру турында еллык докладларга кертелә.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева